ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Мәдәният турында” 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) унынчы абзацта “хезмәт күрсәтүләре” сүзләреннән соң “шартлары” сүзен өстәргә;

б) унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау;”;

в) уникенче абзацта “хезмәт күрсәтүләре” сүзләреннән соң “шартлары” сүзен өстәргә;

г) унөченче абзацта “хезмәт күрсәтүләре” сүзләреннән соң “шартлары” сүзен өстәргә;

д) түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру;”;

е) ундүртенче һәм унбишенче абзацларны тиешенчә унбишенче һәм уналтынчы абзацлар дип санарга;

2) түбәндәге эчтәлекле $V^1$ бүлек өстәргә:

“$V^1$ бүлек. **Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү**

18[1] статья. **Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү**

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү иҗтимагый контрольнең бер төре булып тора һәм мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфаты турындагы мәгълүматны гражданнарга бирү максатларында, шулай ук алар эшчәнлек сыйфатын арттыру максатларында үткәрелә.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү мәдәният оешмасы турындагы мәгълүматның ачык булуы һәм аннан файдалана алу; хезмәт күрсәтүләр шартларының уңайлы булуы; мәдәният оешмалары хезмәткәрләренең яхшы мөнәсәбәттә һәм әдәпле булуы; хезмәт күрсәтүләр шартларыннан канәгать булу, шулай ук инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән файдалана алуы кебек гомуми критерийлар буенча хезмәт күрсәтүләр шартларын бәяләүне күздә тота. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен булдыруны, башкаруны, күрсәтүне һәм интерпретацияләүне гамәлгә ашыручы мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү мәдәният оешмасы турындагы мәгълүматның ачык булуы һәм аннан файдалана алу, шулай ук хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы кебек гомуми критерийлар буенча хезмәт күрсәтүләр шартларын бәяләүне күздә тота.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү "Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре" 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә үткәрелә. Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәргәндә мәдәният оешмалары турында гомуми файдаланудагы, шул исәптән ачык белешмәләр рәвешендә урнаштырылган мәгълүмат файдаланыла.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен булдыруга, башкаруга, күрсәтүгә һәм интерпретацияләүгә карата үткәрелми.

Федераль законнар нигезендә мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын чагылдыра торган күрсәткечләр, шулай ук мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат составы, мондый мәгълүматка карата бердәй таләпләрне дә кертеп, һәм аны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыру тәртибе вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында килгән мәгълүмат кергән көненнән алып бер ай эчендә мәҗбүри каралырга тиеш һәм мәдәният оешмалары эшчәнлеген камилләштерү чараларын әзерләгәндә һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштырыла.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү процедуралары үтәлешен тикшереп тору Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт һәм муниципаль мәдәният оешмалары җитәкчеләре мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрмәгән өчен хезмәт законнары нигезендә җаваплы булалар. Күрсәтелгән мәдәният оешмалары җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләрендә җитәкчеләрнең эш нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм мондый бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планын үтәү нәтиҗәләре кертелә.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы җитәкчесенең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплау һәм аны гомумиләштерү буенча эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләргә дәүләт контрактлары төзү дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы дәүләт контрактларын төзү нәтиҗәләре буенча мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфаты турында мәгълүматны туплауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешманы (алга таба – оператор) билгеләү хакында карарны рәсмиләштерә, шулай ук, кирәк булганда, операторга мондый оешмаларның эшчәнлеге турында дәүләт һәм ведомство статистика хисаплылыгы нигезендә формалаштырыла торган гомуми файдаланырлык мәгълүматны бирә (мәгълүмат оешманың рәсми сайтында урнаштырылмаган очракта).

18$^{2}$ статья. **Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет**

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү өчен шартлар булдыру максатларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы мөрәҗәгате буенча, мондый мөрәҗәгатьне алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән иҗтимагый оешмалар, инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән Татарстан

Республикасы территориясендә урнашкан һәм гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекләр (бәйсез бәяләү җирле үзидарә органнары каршында төзелгән иҗтимагый советлар тарафыннан үткәрелә торган муниципаль мәдәният оешмаларыннан тыш) булган мәдәният оешмалары, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче дәүләтнеке булмаган Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның составын раслый. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча төзелгән иҗтимагый советның составы турында хәбәр итә.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның составы өч елга раслана. Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советны яңа срокка төзегәндә, аның составының кимендә өчтән бере үзгәртелә.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет составына дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, мәдәният өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре керә алмый.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет мондый бәяләү нәтиҗәләре турында фикер алышу һәм аларны формалаштыру өчен үз эшенә мәдәният өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләрен җәлеп итә.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет әгъзалары саны биш кешедән дә ким була алмый. Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында башкара.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан үзенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан мәдәният оешмалары

тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү бер үк оешмага карата иң күбе елына бер тапкыр һәм кимендә өч елга бер тапкыр үткәрелә.

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

бәйсез бәяләү үткәрелә торган мәдәният оешмалары исемлеген билгели;

эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында документлар проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органының оператор белән төзи торган дәүләт контрактлары проектларын карауда катнаша;

оператор тапшырган мәгълүматны исәпкә алып, мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә вәкаләтле органына мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүләр шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук аларның эшчәнлек сыйфатын яхшырту турында тәкъдимнәр тапшыра.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $15^1$ статьяның 1 өлешендәге 12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) $16^1$ статьяның 1 өлешендәге 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрүне тикшереп тору;”;

3) $17^1$ статьяның 1 өлешендәге 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне

оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук федераль законнар нигезендә ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрүне тикшереп тору;”.

**3 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында” 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ел саен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы булган мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм күрсәтелгән оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелә торган чаралар турында мәҗбүри гавами хисап тапшыра. Әлеге хисапта шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре булган мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат та булырга тиеш;”;

2) сигезенче – уникенче абзацларны тиешенчә тугызынчы – унөченче абзацлар дип санарга.

**4 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) $16^1$ пунктта “сыйфатын” сүзен “шартлары сыйфатын” сүзләренә алмаштырырга;

б) $16^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$16^2$) Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау;”;

в) $16^3$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$16^3$) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге хакында мәгълүмат урнаштыру;”;

г) $16^4$ пунктта “сыйфатын” сүзен “шартлары сыйфатын” сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ һәм $12^2$ статьялар өстәргә:

“$12^1$ статья. **Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү**

1. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү иҗтимагый контрольнең бер төре булып тора һәм медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турындагы мәгълүматны гражданнарга бирү максатларында, шулай ук аларның эшчәнлек сыйфатын арттыру максатларында үткәрелә. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү медицина эшчәнлеге сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тикшереп тору, шулай ук медицина ярдәменә экспертиза ясау һәм аның сыйфатын тикшерү максатларында үткәрелми.

2. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү медицина оешмасы турындагы мәгълүматның ачык булуы һәм аннан файдалана алу; медицина хезмәтләре күрсәтү шартларының, шул исәптән медицина хезмәте күрсәтүне көтеп тору вакытының уңайлы булуы; медицина оешмасы хезмәткәрләренең яхшы мөнәсәбәттә һәм әдәпле булуы; хезмәтләр күрсәтү шартларыннан канәгать булу, шулай ук медицина хезмәтләре күрсәтүдән инвалидларның файдалана алуы кебек гомуми критерийлар буенча хезмәтләр күрсәтү шартларын бәяләүне күздә тота.

3. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәргәндә медицина оешмалары турында файдалана алырлык, шул исәптән ачык белешмәләр рәвешендә урнаштырыла торган мәгълүмат файдаланыла.

4. Федераль законнар нигезендә бәйсез бәяләү үткәрелә торган медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын чагылдыра торган күрсәткечләр, шулай ук медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат составы, мондый мәгълүматка карата бердәм таләпләрне дә кертеп, һәм аны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру

өчен рәсми сайтта урнаштыру тәртибе вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органына медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында килгән мәгълүмат кергән көненнән алып бер ай эчендә мәҗбүри каралырга тиеш, һәм ул медицина оешмалары эшчәнлеген камилләштерү чараларын әзерләгәндә һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алына.

6. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштырыла.

7. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү процедуралары үтәлешен тикшереп тору Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында катнаша торган медицина оешмалары җитәкчеләре медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрмәгән өчен хезмәт законнары нигезендә җаваплы булалар. Күрсәтелгән медицина оешмалары җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләрендә җитәкчеләрнең эш нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм мондый бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планын үтәү нәтиҗәләре кертелә.

9. Федераль законнар нигезендә медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы җитәкчесенең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

10. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплау һәм аны гомумиләштерү буенча эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары төзү дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы дәүләт контракты төзү нәтиҗәләре буенча медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплауны һәм аны гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешманы (алга таба – оператор) билгеләү хакында карарны рәсмиләштерә, шулай ук, кирәк булганда, операторга мондый оешмаларның эшчәнлеге турында дәүләт һәм ведомство статистика хисаплылыгы нигезендә формалаштырыла торган файдалана алырлык мәгълүматны бирә (мәгълүмат оешманың рәсми сайтында урнаштырылмаган очракта).

12$^{2}$ статья. **Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет**

1. Медицина оешмаларының хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү өчен шартлар булдыру максатларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы мөрәҗәгате буенча, мондый мөрәҗәгатьне алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән иҗтимагый оешмалар, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләреннән гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Медицина оешмалары тарафыннан (бәйсез бәяләү сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы каршында, җирле үзидарә органнары каршында төзелгән медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советлар тарафыннан үткәрелә торган медицина оешмаларыннан тыш) хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның составын раслый.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органына Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча төзелгән иҗтимагый советның составы турында хәбәр итә.

3. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның (алга таба – Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет) составы өч елга раслана.

4. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советны яңа срокка төзегәндә, аның составының кимендә өчтән бере үзгәртелә.

5. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составына дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, коммерциягә карамаган һөнәри медицина оешмалары вәкилләре, шулай ук медицина оешмаларының җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре керә алмый. Бу чакта Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет мондый бәяләү нәтиҗәләре турында фикер алышу һәм аларны формалаштыру өчен үз эшенә коммерциягә карамаган һөнәри медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләрен җәлеп итә.

6. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары саны биш кешедән дә ким була алмый. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында башкара.

7. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан

Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы сайтында урнаштырылырга тиеш.

8. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

9. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет тарафыннан медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү бер үк медицина оешмасына карата иң күбе елына бер тапкыр һәм кимендә өч елга бер тапкыр үткәрелә.

10. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет:

1) гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнашучы һәм шундый оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрелә торган медицина оешмаларының исемлеген билгели;

2) эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында документация проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органының оператор белән төзелә торган дәүләт контрактлары проектларын карауда катнаша;

3) оператордан алынган мәгълүматны исәпкә алып, медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне башкара;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органына медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук аларның эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр тапшыра.".

**5 статья**

"Мәгариф турында" 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендә:

а) $13^1$ пунктта "белем бирү эшчәнлеге" сүзләреннән соң "шартлары" сүзен өстәргә;

б) $13^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$13^2$) Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет (алга таба – Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет) турында нигезләмәне раслый;";

в) $13^3$ пунктта "белем бирү эшчәнлеге" сүзләреннән соң "шартлары" сүзен өстәргә;

г) $13^4$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13[4]) “Интернет” челтәрендә үзенең рәсми сайтында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфаты турында гражданнарның фикерләрен белдерү өчен техник мөмкинлек тәэмин итә;”;

д) түбәндәге эчтәлекле 13[5] пункт өстәргә:

“13[5]) “Интернет” челтәрендәге үзенең рәсми сайтында Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыра;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 3[1] бүлек өстәргә:

“3[1] бүлек. **Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү**

25[3] статья. **Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү**

1. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрдә катнашучыларга гомуми файдаланырлык мәгълүмат нигезендә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру эшен оештыру дәрәҗәсе турында мәгълүмат бирү максатларында үткәрелә.

2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү җинаять-үтәү системасында төзелгән мәгариф оешмаларына карата, шулай ук белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Федераль законның 81 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән федераль дәүләт оешмаларына карата үткәрелми.

3. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү Федераль закон нигезендә башкарыла. Оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар турында мәгълүматның ачык булуы һәм аннан файдалана алу; белем бирү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган шартларның уңайлы булуы; хезмәткәрләрнең яхшы мөнәсәбәттә һәм әдәпле булуы; оешманың белем бирү эшчәнлеген алып бару шартларыннан канәгать булу, шулай ук хезмәтләр күрсәтүдән инвалидларның файдалана алуы кебек гомуми критерийлар буенча үткәрелә.

4. Федераль законнар нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын чагылдыра торган күрсәткечләр, шулай ук шушы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат составы, мондый мәгълүматка карата бердәм таләпләрне дә кертеп, һәм аны “Интернет” челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру

өчен рәсми сайтта урнаштыру тәртибе вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнә.

5. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” челтәрендә дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштырыла.

6. Оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү процедуралары үтәлешен тикшереп тору Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль оешмалар җитәкчеләре оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрмәгән өчен хезмәт законнары нигезендә җаваплы булалар. Күрсәтелгән оешмалар җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләрендә җитәкчеләрнең эш нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм мондый бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планын үтәү нәтиҗәләре кертелә.

8. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы органы җитәкчесенең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

9. Оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплау һәм аны гомумиләштерү буенча эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары төзү дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алулар өлкәсендә контракт системасы хакында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы дәүләт контрактлары төзү нәтиҗәләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплауны һәм аны гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешманы (алга таба – оператор) билгеләү хакында карарны рәсмиләштерә, шулай ук, кирәк булганда, операторга мондый оешмаларның эшчәнлеге турында дәүләт һәм ведомство статистика хисаплылыгы нигезендә формалаштырыла торган гомуми файдаланудагы мәгълүматны бирә (мәгълүмат оешманың рәсми сайтында урнаштырылмаган очракта).

### $25^4$ статья. **Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет**

1. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү өчен шартлар булдыру максатларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы,

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен башкаручы органы мөрәҗәгате буенча, мондый мөрәҗәгатьне алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, белем алучыларның һәм (яисә) балигъ булмаган белем алучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән иҗтимагый оешмалар, инвалидларның иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының, шулай ук муниципаль мәгариф оешмаларының (бәйсез бәяләү җирле үзидарә органнары каршында төзелгән иҗтимагый советлар тарафыннан үткәрелә торган муниципаль мәгариф оешмаларыннан тыш) һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, мәгариф эшчәнлеген Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләре исәбенә башкаручы башка оешмаларның Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның составын раслый.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органына Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча шушы орган каршында төзелгән иҗтимагый советның составы турында хәбәр итә.

3. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның составы өч елга раслана. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советны яңа срокка төзегәндә, аның составының кимендә өчтән бере үзгәртелә.

4. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның составына дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, мәгариф өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, бу өлкәдә эшчәнлек алып бара торган оешма җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре керә алмый. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет мондый бәяләүнең йомгаклары турында фикер алышу һәм аларны формалаштыру өчен үз эшенә мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләрен җәлеп итәргә мөмкин.

5. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет әгъзалары саны биш кешедән дә ким була алмый. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында башкара.

6. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмә Татарстан

Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

8. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү бер үк оешмага карата иң күбе елына бер тапкыр һәм кимендә өч елга бер тапкыр үткәрелә.

9. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) бәйсез бәяләү үткәрелә торган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеген билгели;

2) эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алу турында документация проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан оператор белән төзелә торган дәүләт контрактлары проектларын карауда катнаша;

3) оператор тарафыннан бирелгән мәгълүматны исәпкә алып, мәгариф эшчәнлеген башкара торган оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне башкара;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча нәтиҗәләрне, шулай ук аларның эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр тапшыра.”.

**6 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 2 өлешендә:

а) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10) Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмә раслауны;”;

б) 11 пунктта “хезмәт күрсәтүләр” сүзләрен “хезмәтләр күрсәтү шартлары” сүзләренә алмаштырырга;

в) 12 пунктта “хезмәт күрсәтүләрнең” сүзләрен “хезмәтләр күрсәтү шартлары” сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ һәм $9^2$ статьялар өстәргә:

“$9^1$ статья. **Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү**

1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү иҗтимагый контрольнең бер төре булып тора һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүматны социаль хезмәтләрдән файдаланучыларга бирү максатларында, шулай ук аларның эшчәнлек сыйфатын арттыру максатларында үткәрелә.

2. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү социаль хезмәт күрсәтү оешмасы турында мәгълүматның ачык булуы һәм аннан файдалана алу; социаль хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән аларның күрсәтелүен көтеп тору вакыты шартларының уңайлы булуы; социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренең ихтирамлы һәм әдәпле булуы; хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатыннан канәгать калу, шулай ук хезмәтләр күрсәтүдән инвалидларның файдалана алуын күздә тота.

3. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль закон нигезендә үткәрелә. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәргәндә социаль хезмәт күрсәтү оешмалары турында гомуми файдаланудагы, шул исәптән ачык белешмәләр рәвешендә урнаштырыла торган мәгълүмат файдаланыла.

4. Үзләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәяләүнең гомуми критерийларын чагылдыра торган күрсәткечләр, шулай ук әлеге оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат составы, мондый мәгълүматка карата бердәм таләпләрне дә кертеп, һәм аны “Интернет” челтәрендә дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыру тәртибе федераль законнар нигезендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органына социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында килгән мәгълүмат бер ай эчендә мәҗбүри карарыга тиеш һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшчәнлеген камилләштерү чараларын әзерләгәндә һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә исәпкә алына.

6. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан үзенең рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр хакында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштырыла.

7. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү процедуралары үтәлешен тикшереп тору Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары җитәкчеләре социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрмәгән өчен хезмәт законнары нигезендә җаваплы булалар. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләрендә җитәкчеләрнең эш нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм мондый бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планын үтәү нәтиҗәләре кертелә.

9. Федераль законнар нигезендә социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органы җитәкчесенең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

10. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплау һәм аны гомумиләштерү буенча эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын төзү дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алулар өлкәсендә контракт системасы хакында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат туплауны һәм аны гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешманы (алга таба – оператор) билгеләү хакындагы карарны рәсмиләштерә, шулай ук, кирәк булганда, операторга әлеге оешмаларның эшчәнлеге турында дәүләт һәм ведомство статистика хисаплылыгы нигезендә формалаштырыла торган гомуми файдаланудагы мәгълүматны бирә (мәгълүмат оешманың рәсми сайтында урнаштырылмаган очракта).

### $9^2$ статья. **Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет**

1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар булдыру максатларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органы мөрәҗәгате буенча, мондый мөрәҗәгатьне алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында төзелгән иҗтимагый оешмалар, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре, ветераннарның иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә куелган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, шулай ук социаль хезмәтләрне Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбенә күрсәтүче дәүләтнеке булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр

күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет төзи һәм аның составын раслый.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органына Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча төзелгән иҗтимагый советның составы турында хәбәр итә.

3. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советның составы өч елга раслана.

4. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советны яңа срокка төзегәндә, аның составының кимендә өчтән бере үзгәртелә.

5. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет составына дәүләт хакимияте органнары, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре керә алмый. Шул ук вакытта Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет мондый бәяләү нәтиҗәләре турында фикер алышу һәм аларны формалаштыру өчен үз эшенә социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы вәкилләрен җәлеп итә.

6. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет әгъзалары саны биш кешедән дә ким була алмый.

7. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычларында башкара.

8. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органының “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

9. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү бер үк оешмага карата иң күбе елына бер тапкыр һәм кимендә өч елга бер тапкыр үткәрелә.

10. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый совет турында нигезләмә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

11. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет:

1) бәйсез бәяләү үткәрелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары исемлеген билгели;

2) эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алу турында документация проектларын, шулай ук оператор белән төзелә торган дәүләт контрактлары проектларын карауда катнаша;

3) социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәяләүне оператор тапшырган мәгълүматны исәпкә алып башкара;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле органына социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук аларның эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәр тапшыра.”.

**7 статья**

“Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

“$1^1$. Иҗтимагый палата законнар нигезендә мәдәният, сәламәтлек саклау, белем бирү, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча иҗтимагый советлар төзи.”.

**8 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 июль
№ 55-ТРЗ